РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ
ТЕТЮШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТӘТЕШ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422370 г.Тетюши, ул. Малкина, 39
422370 Тәтеш шәһәре, Малкин ур., 39
тел. (84373) 2-50-02, 2-53-33, факс 2-62-48, e-mail: tatesh@tatar.ru
ОКПО 78702080, ОГРН 1061672000026, ИНН/КПП 1638004985/163801001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** 28.04.2020

**КАРАР** № 219

**Тәтеш муниципаль районы башкарма комитетының «Муниципаль учреждениеләргә карата муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә (эшләр башкаруга) муниципаль заданиене формалаштыру һәм муниципаль йөкләмәне үтәүне финанс белән тәэмин итү тәртибе турында»гы 2017 елның 4 апрелендәге 141 номерлы карары кушымтасына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә, Тәтеш муниципаль районы башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Тәтеш муниципаль районы башкарма комитетының «Муниципаль учреждениеләргә карата муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә (эшләр башкаруга) муниципаль заданиене формалаштыру һәм муниципаль йөкләмәне үтәүне финанс белән тәэмин итү тәртибе турында»гы 2017 елның 4 апрелендәге 141 номерлы карары кушымтасына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Кушымтаның 1 бүлегендәге 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә «Муниципаль бирем күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләрнең (башкарыла торган эшләрнең) сыйфатын һәм (яки) күләмен (эчтәлеген) тасвирлый торган күрсәткечләр, муниципаль йөкләмәнең үтәлешен контрольдә тоту тәртибе, шул исәптән аны вакытыннан алда туктату шартлары һәм тәртибе; муниципаль йөкләмәне үтәү турындагы хисапка таләпләр. Физик һәм юридик затларга муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә муниципаль йөкләмә шулай ук үз эченә алырга тиеш:

тиешле хезмәтләрне кулланучылар булып торучы физик һәм (яки) юридик затларның категорияләрен билгеләү;

тиешле хезмәтләр күрсәтү тәртибе;

физик яки юридик затлар тарафыннан тиешле хезмәт күрсәтүләр өчен түләүгә иң чик бәяләр (тарифлар), әгәр Россия Федерациясе законнарында аларны түләүле нигездә күрсәтү каралган булса, йә күрсәтелгән бәяләрне (тарифларны) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән очракларда билгеләү тәртибе».

2. Әлеге карарны Тәтеш муниципаль районы сайтында бастырып чыгарырга һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Тәтеш муниципаль районы**
**башкарма комитеты**
**җитәкчесе** **А.Б. Семенычев**